ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**23 октябрь 2020 ел** **№ 4**

**Красносельский авыл җирлеге Советынын 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль район Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган (2018 елның 24 сентябрендәге 96 нчы номерлы Совет карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасарының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү

чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (2018 елның 24 сентябрендәге 96 нчы номерлы Совет карары редакциясендә) карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә 2020 елның 1 октябреннән Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (Советның 2018 елның 24 сентябрендәге 96 номерлы карары редакциясендә) карары белән расланган 2 нче кушымта, таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасарының айлык акчалата түләү күләме»

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 10 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | 13968 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге тиешле финанс елына бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар рәсми басылып чykkаннан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Никитенко Р. Р. йөкләргә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин